| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

***Постановление*** ***Карар***

**23.10.2019** **Чистай шәһәре** **№ 557**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
27 нче февралендәге 100 нче номерлы
“Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында
“Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең
(балалар бакчалары) төп гомуми белем
бирү программасын тормышка ашыручы
белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү”
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында”гы
карарына узгәрешләр кертү турында

29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273нче Федераль закон, 27.07.2010 елгы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.03.2015 елгы ”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларынаисәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административрегламентының үрнәк формасын раслау турында”гы 1389/15нче Боерыгы белән,Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 нче февралендәге 100 нче номерлы “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында “Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.2 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, инвалид булган, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары хәрбиләре һәм органнары, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләре, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән һәм контртеррористик операцияләрдә катнашкан һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин иткән затларның, Россия Федерациясенең милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт иткән һәм махсус полиция

исемнәренә ия, Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә террорчылык акцияләрен оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучы террор оешмалары һәм төркемнәре, аларның лидерлары һәм затлары, шулай ук Берләшкән гаскәрләр (көчләр) төркеме хезмәткәрләре һәм хәрбиләре тарафыннан Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә терроризмга каршы операцияләр үткәрү буенча махсус көчләр составына керүчеләрнең балалары”;

1.2. 1.2 пунктының 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, янгынга каршы Федераль хезмәттә һәм Россия Федерациясе таможня органнарында махсус исемнәре булган һәм хезмәт итүче хезмәткәрләрнең балалары (алга таба-хезмәткәрләр); хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта гарипләнгән, яки сәламәтлегенә зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрнең балалары; учреждениеләрдә һәм органнарда хезмәт итү чорында хасталанган авыру нәтиҗәсендә вафат булган хезмәткәрнең балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә алынган һәм учреждениеләрдә һәм шуның нәтиҗәсендә органнарда алга таба хезмәт итү өчен физик мөмкинлеге булмаган, шунлыктан хезмәттән киткән, яисә сәламәтлегенә башка зыян күргән Россия Федерациясе гражданының балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта алынган авыру нәтиҗәсендә, сәламәтлекнең гарипләнүе, яисә башка зыян күрү аркасында, яисә хезмәт итү чорында учреждениеләрдә һәм органнарда авыру нәтиҗәсендә алга таба хезмәт итү мөмкинлеген булмаган һәм эштән азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булган Россия Федерациясе гражданинының балалары; хезмәткәр тәрбиясендә булган балалар»;

1.3. 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | исәпкә кую өлешендә:<br>- баланың яше Оешмага кабул ителә торган максималь яшьтән артып китү;<br>Оешмага кабул итү өлешендә:<br>-“Электрон балалар бакчасы”системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау. | 29.12.2012 елда кабулителгән “РоссияФедерациясендә белембирү турында”гы273нче Федераль закон |
| Муниципаль хезмәткүрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1) исәпкә кую өлешендә:<br>- баланың туу турындагы таныклыгы мәгълүматларын идентификацияләүгә комачаулаучы дөрес булмаган (җитәрлек түгел) белешмә бирү;<br>- баланың яше Оешмага кабул ителә торган максималь яшьтән артып китү;<br>Оешмага кабул итү өлешендә:<br>- үзең теләгән Оешмадагы тәрбияләү һәм укыту теленең үзең теләгән тәрбияләү һәм укыту теленә туры килмәве;<br>2) Оешмага кабул итү өлешендә:<br>-“Электрон балалар бакчасы” системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау;<br>- медицина күрсәткечләре буенча билгеләнгән Оешмага баланы йөртү тыела;<br>- әти-әнисенең (законлы вәкиленең) муниципаль хезмәт алудан баш тартуы | 29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273нче Федераль закон;<br>Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августында кабул иткән “Төп гомуми белем программалары – мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында”гы 1014нче Боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | турында гариза.<br>2012 елның 29 декабрендәге “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә һәм 88 статьясында каралган очраклардан тыш, муниципаль белем бирү оешмасына кабул итү, бары тик анда буш урыннар булмау сәбәпле генә кире кагылырга мөмкин.<br>Әгәр дә буш урыннар булмау сәбәпле кире мәсьәлә уңай чишелми икән, баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры мәгариф өлкәсендә идарә итүче җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәләр» | |

2. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУнә (О.В. Купцова) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында: http://chistopol.tatarstan.ru/ һәм хокукый-мәгълүматның рәсми интернет-порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы О. В. Купцовага йөкләргә.

Бшакарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов